**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 22 июня** **№ 261**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2017 елның 19 апрелендәге 90 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2017 елның 19 апрелендәге 90 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр;»;

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр;»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек контролендәге хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре, хуҗалык партнерлыгы;»;

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль берәмлекләр тарафыннан фонд рәвешендә төзелгән коммерциягә карамаган оешмалар;»;

3.3 пунктта:

10 пунктчада «авыл хуҗалыгын үстерү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлеккә кертелгән һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

«17», «18» саннарын тиешенчә «11», «12» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Советы рәисе** **Н.А.Вазыйхов**